**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Әлки**
**муниципаль районы**
**Юхмачы авыл җирлеге**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**Исполнительный комитет**
**Юхмачинского сельского**
**поселения**
**Алькеевского муниципального района**

Адресы: 422885, ТР, Әлки районы,
Юхмачы авылы, Ленин урамы ,1а
Тел./факс 8(84346) 74-224

Адрес:422885, РТ, Алькеевский
район, с. Юхмачи, ул.Ленина, д.1а
тел./факс 8(84346) 74-224

ПОСТАНОВЛЕНИЕ Юхмачы ав. КАРАР

2025 елның 09 июне № 28

Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Юхмачы авыл җирлеге территориясендә йорт хайваннарын йөртү урыннарын билгеләү турында

06.10.2003 елның 131-нче Федераль Законы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында», 27.12.2018 елның 489-нче Федераль Законы «Хайваннар белән җаваплы эш итү һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында», Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының « Юхмачы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы таянып, Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Юхмачы авыл җирлеге Башкарма комитеты **КАРАР КАБУЛ ИТӘ:**

1. Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының « Юхмачы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә йорт хайваннарын йөртү өчен түбәндәге урыннарны билгеләргә:

1.1. Файдаланудагы яисә хуҗа милкендәге җир кишәрлекләре;

1.2. Халык күпләп җыелмый торган авыл җирлеге территориясендә торак сектор һәм җәмәгать урыннары артындагы урыннарда, борындыкларда һәм тезгендә аларның хуҗалары күзәтүе астында:

- Юхмачы авылында Мәктәп урамы артында, якынча ( координатлары 54.628501 54.625615).

Әлеге территориядә «Йорт хайваннарын йөртү»дигән язулы табличка урнаштырырга.

2. Әлеге карарны "Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында" түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru хәм Әлки муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Әлки муниципаль районының
Юхмачы авыл җирлеге
Башкарма комитет җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы А.В.Тутеров